СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №78 (7251) | 29 июнь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## Басуда эш бара

**«Родина» колхозы.** Сабан бодаен гербицид белән эшкәртү белән Виталий Николаевич Герасимов мәшгуль. Аның МТЗ-80 тракторын кырда нәкъ технология таләп иткән вакытларда күрәсең: төнге өчтән—тугызгача һәм көндезге 15 сәгатьтән 21 сәгатькә кадәр ул ОПШ-15 сиптергече белән үзенә йөкләнгән вазифаны җиренә җиткереп башкара. Механизаторны су белән тәэмин итеп торуда Егор Иванович Волков һәм заправкалаучылар Василий Федорович Сандрюхин, Юрий Семенович Сандрюхин да әйбәт хезмәт куялар.

**В. САНДРЮХИН,**
баш агроном.

## Күңел биреп

«Игенче» колхозында бер кат чәчелгән шытымнар тигез булып тишелмәделәр. Хәзер 300 гектар мәйдан биләгән бу чөгендер басуында Т-40 тракторлары белән Таһир Гомәров, Вәзир Гобәйдуллин, Фәрит Хисмәтов, Вәли Сөләйманов рәт араларын эшкәртә.

Колхозчы хатын-кызлар исә сирәкләү эшләрен башкаралар.

Хуҗалыкка ярдәмгә 53 нче төзү-монтаж идарәсе, «Вторчермет» эшчеләре дә килделәр.

Татлы тамырның 19 гектары Фома урта мәктәбе укучылары карамагында.

**В. КАНЯФИНА,**
экономист.

## УҢГАН МЕХАНИЗАТОР

**«Алга» колхозы.** Чөгендер игүче Шәүкәт Миндубаевны хуҗалыкта тырыш, уңган кеше буларак яхшы беләләр. Елның-елында туган колхозының татлы тамыр плантацияләрендә карусыз хезмәт куя ул.

Быел, беренче кат чәчелгән шытымнар начар тишелгәч, колхоз 215 гектар мәйдан җирнең 42 гектарын яңабаштан чәчкән иде. Шуңа да Шәүкәт Миндубаевка үзенең Т-70 тракторы белән бу мәйдандагы рәт араларын бераз соңгарак калып эшкәртергә туры килде.

Шәүкәт кукуруз рәт араларын эшкәртүдә дә, чүп үләннәренә каршы гербицид сибүдә дә актив катнашты. Алар Т-70 тракторчысы Наил Яруллин белән бергәләп эшләделәр.

**Ә. САФИУЛЛИН.**
«Алга» колхозы.



«Комбайн» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында Әминә Мифтаховна Әһлиуллина ике дистә елдан артык хезмәт куя. Шул дәвер эчендә ул үзен булдыклы һәм уңган сыер савучы итеп танытып өлгерде.

Хәзерге вакытта Әминә Мифтаховна үз группасындагы һәр сыердан тәүлегенә уртача 13 килограмм сөт сава.

Маллар бүгенге көндә урман буендагы табигый болынлыкларда көтелә, янәшәдә генә җәйге лагерь да. Яхшы һава торышын һәм куе булып үскән үләннәрне искә алганда, продуктны арттыру өчен мөмкинлекләр җитәрлек, бары җиң сызганып эшлисе генә.

Әминә Мифтаховнаның балалары да бәхет эзләп читкә китмәделәр. Өлкән кызлары Әлфинур шул ук товарлыклы-сөтчелек фермасында сыер савучы, улы Фәрит тракторчы булып эшлиләр.

Әнә шулай сыер савучы Әминә Мифтаховна Әһлиуллина бәхетне эштә һәм гаиләсендә тапты.

Рәсемдә: сыер савучы Ә. М. Әһлиуллина.
Н. Азизов фотосы.

## Киңәшмә үтте

27 июнь көнне КПСС райкомы бинасында КПСС райкомы аппараты, шәһәр оешмалары, промышленность предприятиеләре җитәкчеләре катнашында киңәшмә булды.

Анда җәйге азык әзерләү, урып-җыю чорында колхоз-совхозларга техника, эшче көчләр белән булышу мәсьәләсе каралды. Бу шимбә-якшәмбе районда терлек азыгы хәзерләү буенча удар ике көнлек игълан ителгәнлектән, анда оешма-предприятиеләрдән автотранспорт бүлү кирәклеге әйтелде. Урып-җыю чорында колхоз-совхозларга ярдәмгә җибәреләсе техниканы 10 июльгә әзерлек сызыгына кую, алары механизаторлар, шоферлар белән комплектлау кирәклеге ассызыкланды. Боларның һәммәсе районда төзелгән урып-җыю комплексын оештыру штабы игътибарында тора.

Киңәшмәдә районда юл ремонтлау һәм төзү буенча удар икеайлык барышына күзәтү дә ясалды.

Киңәшмәдә катнашучылар алдында әлеге мәсьәләләр буенча район Советы рәисе, КПСС райкомы секретаре Х. Х. Морадыймов чыгыш ясады.

Яңалык

## Казанга автобус йөриячәк

Уфа-Казан пассажир поезды хәрәкәте туктау сәбәпле безнең Октябрь һәм республиканың бу төбәктәге башка районнары халкына Казанга бару кыенлашты.

Шушы хәлләрне искә алып Норлат-Октябрь АТПсы җитәкчелеге якын араларда пассажирлар йөртү өчен Норлат—Яңа Чишмә—Казан автобусы маршруты ача. Автобус көн саен булачак. Хәзерге вакытта моның өчен кирәкле техник документлар хәзерләнә. Инде яңа ЛАЗ-695 автобусы алынды. Тиздән икенче автобус та кайтачак.

Маршрутның ачылу көне, хәрәкәтнең вакыты турында өстәмә рәвештә хәбәр ителәчәк.

**В. ЖУЛИН,**
АТПның кадрлар бүлеге өлкән инспекторы вазифаларын үтәүче.

## Кем ничек эшли?

Кырларга ашлама чыгаруның барышы.

Беренче багана — хуҗалыклар исемнәре, икенче—органик ашлама чыгару буенча җиткерелгән план (тонналарда), аның үтәлеше (процентларда), удар икеайлыкта чыгарылган ашлама (тонналарда).

Мәгълүматлар 1991 елның 28 июненә.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Синдряков исем. | 16500 | 26 | 1042 |
| Ульянов исем. | 21300 | 22 | — |
| «Правда» | 15800 | 2 | 315 |
| «Восход» | 15400 | 32 | 1450 |
| Мичурин исем. | 16200 | 24 | 3350 |
| «Россия» | 14200 | 70 | 4871 |
| Хафизов исем. | 15900 | 50 | 1400 |
| «Путь к коммунизму» | 21900 | 5 | 890 |
| Муса Җәлил исем. | 12800 | 35 | 2400 |
| «Родина» | 11700 | 1 | 35 |
| «Игенче» | 20000 | 50 | — |
| «Большевик» | 15400 | 5 | — |
| «Заветы Ильича» | 16200 | 24 | 1800 |
| «Знамя Октября» | 18500 | 43 | 6000 |
| «Алга» | 32000 | 3 | 839 |
| «Комбайн» | 24400 | 54 | 3670 |
| XXI партсъезд исем. | 31100 | 29 | 8500 |
| «Татарстан» | 16400 | 29 | 2300 |
| «40 лет Победы» | 15000 | 53 | 6000 |
| «Чишмә» | 19000 | 14 | 200 |
| «Таң» | 12900 | 43 | 2520 |
| «Москва» | 15800 | 5 | 300 |
| «Үрнәк» | 9400 | 1 | — |
| «Лесная Поляна» | 3000 | — | — |
| «Кондырча» | 8000 | 48 | 182 |
| Кузнецов исем. | 15000 | 43 | 410 |
| «Заря» | 12400 | 87 | 725 |
| «Чирмешән» | 8900 | 69 | 4187 |
| «Ленинский путь» | 15600 | 20 | 3150 |
| «1 нче май» | 18000 | 18 | — |
| «Төрнәс» совхозы | 24000 | 26 | 3100 |
| «Мамык» совхозы | 19000 | 17 | 550 |
| «Рассвет» совхозы | 32000 | 56 | 3493 |
| «Сөлчә» совхозы | 14000 | 29 | 1080 |
| Хуҗалыкара берләшмә | 15700 | 89 | 5200 |
| «Яшь көч» | 5800 | 200 | 10630 |
| Район буенча | 599000 | 33 | 80589 |

Мәгълүматлардан күренгәнчә, аерым хуҗалыклар кырларга өстәмә сый бирүгә бик җавапсыз карыйлар. Басуларның уңдырышлылыгын күтәрүдә алыштыргысыз булган органика чыгаруга игътибарны арттыру зарур.

### Игътибар: газета юбилей үткәрә

## Хөрмәтле газета укучылар!

Мәгълүм булганча, 1991 елның 6 июлендә «Дуслык» («Дружба», «Туслах») район газетасы үзенең 60 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк. Бу көнне шәһәрнең үзәк мәйданында зур бәйрәм үткәрелә.

Ул көнне сезнең игътибарга 8.00 сәгатьтә—җирле радионың махсус чыгарылышы (ул район буенча трансляцияләнә);

8.30 сәгатьтә культура программасы—район үзешчән сәнгатьтә катнашучылар концерты, тынлы оркестр чыгышы тәкъдим ителә;

9.00 сәгатьтә «Дуслык» газетасы призына төрле күңелле ярышлар: 500 метрга йөгерү, капчык киеп йөгерү, көянтә белән һәм кашык кабып йөгерүләр, аркан тарту, уенчыклар кисү, чүлмәк вату, картингистлар узышы, «Дуслык» темасына асфальтта иң яхшы рәсемнәргә конкурс башлана.

10.00 сәгатьтә викторина үткәрелә.

11.00 сәгатьтә район культура йортында зур юбилей тантанасы була. Бу көнне «Норлатнефть» НГДУсы, тимер юлчылар, урман промышленносте хуҗалыгы эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре, райпо буфетлары, лареклары һәм «Союзпечать, райпо киосклары эшләячәк.

15.00 сәгатьтә бәйрәм яшьләр өчен культура һәм ял паркында дәвам итәчәк. Анда милли көрәш, капчык сугышы, китап аукционы оештырыла, үзешчән сәнгать көчләре әзерләгән концерт була, барлык аттракционнар һәм буфет эшли.

Бәйрәмгә республика газета һәм журналлары, күрше район газеталары редакторлары, колхоз-совхозлар, предприятие, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләре, партия һәм комсомол оешмалары секретарьлары, авыл Советлары рәисләре, район һәм җәмәгать оешмалары җитәкчеләре, җәмәгать корреспондентлары, «Дуслык» газетасы активистлары кунак булып киләчәк.

Сезне, хөрмәтле укучылар, шулай ук безнең белән газета юбилеен бәйрәм итәргә чакырабыз.

**РӘХИМ ИТЕГЕЗ!**



## Бөек Ватан сугышы башлануның 50 еллыгына карата

# Хәбәрсез югалган солдатлар

Фатыйх чираттагы минаны зарарсызландыру белән шулкадәр мавыккан иде, беренче мәлне артында торган юлдашы аңа орынып киткән шикелле тоелды, артына күз салды. Юлдашы күренмәде. Минадан ачылган кырдан аның эзеннән килүче танк 100 метрлар артта иде әле. Аркасы буйлап кайнар сыеклык агылганын тойгач кына яралануын аңлады. Немец снайперы аның башына төзәгәнен, соңгы моментта мина запалын борганда хәрәкәтләнүе сәбәпле пуля иңбашына эләгүен, үпкәсенә җитеп тукталуын соңрак аңлады.

Бу 1942 елның мартында булды. Аңа кадәр Фатыйх махсус сапер батальоны составында көнбатыш Белоруссиядән Мәскәү астына кадәр чигенде. Батальонга ул этапта аэродромнар тигезләү, юллар хәзерләү йөкләтелгәнгә алар гаскәрләрдән алдарак чигенә бардылар, камалышларга эләкмәделәр. Мәскәү астында контрһөҗүм башлангач, аларга да яңа бурыч йөкләтелде: танк берләшмәсенә юл ачып, минадан арындырып барырга тиеш булдылар.

Госпитальдә үпкәдәге пуляны алмадылар: катлаулы операция кирәк иде. Беркадәр сәламәтләнгәч аны, сугышка яраксыз санап, кайтарып җибәрделәр: җәрәхәт ябылмаган, ютәлләгән саен кан килә иде.

Ул Киеклегә кайтканда аларның нигезендә үзгәрешләр күп иде. Абыйлары Мингәрәй, Минзакир, энесе Ислам да сугышта. Галиәскәр колхозда эшләп йөри. Әтисе Мингалим, әнисе Хөбәйбә дә нык бирешкәннәр. Колхозда эшләсәң-эшләмәсәң дә түләү юк. Үз гаиләләре өстенә Мингәрәй абыйсының өч баласы алар өстенә: әниләре үги булгач, көннәре бабасы белән әбисе янында уза.

Инде май ае барса да ындырда былтыргы эскерт ашлыгын сугалар. Фатыйх шулар янына барып, эшкә алынып карый: болай да кан түкергән кешегә кая инде ул тузан эчендә түзәргә. Авыр күтәрергә, тешерергә дә ярамый, ә колхозда шуннан гайре, бигрәк тә ул заманада, нинди хезмәт бар.

Үз-үзеннән гарык була Фатыйх: балалар өлешен ашап ятсынмы? Үлсәм сугышта үләрмен, ичмасам олылап телгә алырлар дип фронтка җибәрүне сорап хәрби комиссариатка килә. Үзе сорагач, сәламәтлеге буенча яраксыз дип тормыйлар, хәрәкәттәге, армиягә озаталар. Сугыш вакытында солдат озату планы туламы соң?

Мингалим карт, күңеле сизенгән икән, улы белән бәхилләшеп аерылыша. Үз хәлен үзе чамалаган күрәсең: Мингәрәйнең үле хәбәрен алуга чирләп урын өстенә егыла. Хөбәйбә карчыкка барыннан да авырга туры килә ул вакытларда. Карты озакта үтми үлеп китә. 17 яше тулып узган Галиәскәрне дә, аны җирләүгә солдатка алалар. Ире үлгән хәбәрне алгач, үги балаларын тулысынча аңа калдырып килене дә Норлатка күчеп китә. Торма өстенә тоз дигәндәй, нәкъ шул вакытларда Төньяк Кавказга барып эләккән Фатыйх Миннебаевның үлүе турында кара мөһерле кәгазь килеп төшә.

Түзә ана йөрәге. Калган балалары, оныклары хакына күтәрә бу кара сагышны. Алар бәхетенәдер инде, күрше Аксубай районының МЮД совхозыннан ягулык ташучы атлылар аларга туктала башлыйлар. Фатир тоткан өчен совхоз, килешү нигезендә, паек һәм айга 5 литр керосин бирә. Ач үлемнән карчык һәм аның оныклары шулай котылып калалар.

Ә еракта сугыш дәвам итә. Аңа хат ташучыны күрүгә үзе курка, үзе хәбәр көтә. Хезмәт армиясенә эләккән Минзакиры, әле солдат һөнәре серләренә өйрәнеп йөрүче Галиәскәре өчен дә түгел. Исламы өчен курка ул.

Ислам 1942 ел башыннан бирле ут өермәсе эчендә йөри. Ленинград юнәлешенә Төнья-Көнбатыш фронтка эләгә ул. Яраланып, госпитальдә ятып чыккач, исеме күпләргә мәгълүм 54 нче (Ленинград блокадасын тыштан өзү өчен сугыш хәрәкәтләре алып бара ул) армиянең бер дивизиясе штабына эләгә.

Танк частенә күчкәч, 1943 елның көзендә танк коручы Миннебаевның тормышы адым саен куркыныч астында.

1943 елның октябрендә Крести станциясе өчен сугышларда күпне кичерергә туры килә танкист башына. Аларның ротасын таң алдыннан сугыш белән сынап карау өчен җибәрәләр. Дошманның ут нокталары, җанлы көче дә ачыклана. Ләкин бик кыйммәт бәһага төшә ул: 7 танкның берсе Миннебаевларныкы гына исән чыга. Икенче, яңа һөҗүм вакытында ул юл салып, әйдәп барырга тиеш була.

Станция өчен сугышлар уңышлы тәмамлана. Бу районда шактый дошманны әсир төшерәләр. Бу сугышта күрсәткән батырлыклары өчен экипаж членнары хөкүмәт бүләкләренә лаек була. Ислам Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Һөҗүм хәрәкәтләре дәвам итә. 31 декабрь көнне аларның танк подразделениесе чираттагы торак пункт өчен сугыш башлый. Исеме хәтердә сакланмаган кечкенә бу авыл урамына килеп кергәч немецлар контратакага ташлана, безнең Т-34ләргә каршы «Тигр», «фердинанд»лар каршы чыга.

Алдан Исламнар танкысының чылбыры өзелә. Ул инерция буенча борыла һәм «йомшак ягын» дошманга куя. Шулчак броняны шартламый торган снаряд, (хәрбиләр телендә аны болванка дип йөртәләр) тишеп керә. Танк яна башлый. Механик люгы аша алар танктан чыгып чигенә башлыйлар. Ислам яралы була инде, чылбыр эзеннән кире килгән якка чигенә. Бер йортның бакчасы турына җиткәч кенә тагын снаряд шартлый.Ул егыла, аңын җуя.

—Бу бәрелештә мин нейтраль зонада калганмын, дип искә ала Ислам Мингалимович үзе. — Төнлә алып чыгып кыр госпиталенә озатканнар.

Аны ярдәмгә килгән часть сугышчылары коткарган булса кирәк, чөнки үзенекеннән авылга алдан «хәбәрсез югалды», тагын күпмедер узгач, «батырларча һәлак булды», дигән хәбәр килеп төшә. Ана инде өченче улы өчен дога кыла, ясин чыга, ходайдан калган балаларын саклауны сорап ялвара. Ул да түгел Галиәскәр Галимов (фамилиясен, әтисе исеменнән кыскартып армиядә шулай язганнар) яралануы турында хат килеп төшә. Артиллерия разведчигының хезмәте дә четрекле, гел дошман уты астында. Ана баласының җәрәхәтләнүе өчен көенсә, исән калганына шөкер кола.

Шулай үз-үзен кая куярга белми йөргән көннәрнең берсендә өчпочмаклы солдат хаты килеп төшә. Ислам, үлемгә үч иткәндәй—исән калган икән. 7 җирдән җәрәхәтләнгән булса да, бер аягы бот төбеннән үк киселсә дә, яшь организм үлемнән көчлерәк булып чыга. 10 айга якын госпитальдән-госпитальгә йөреп култык таягы белән атлар хәлгә килгәч әнисенә хат яза: үзенең исән булуын, инвалидлар йортына китәргә исәпләвен хәбәр итә. Ана өчен бала артык булмамы соң: бер генә түгел, ике аягың булмаса да өйгә кайт, дип хат сала.

Кайтып 18 көн үтүгә укытучы Әсма йортка килен булып төшә. Ислам клуб мөдире: хатыны мәктәптә—тормыш үз эзенә төшә. Сугыш беткән көздә хәзерге җиде балаларының беренчесе— Роза туа.

Хөбәйбә апа, бишек җырын көйли-көйли бала йоклатканда кайта алмый калган улларын сагынып күз яшьләрен коя тора. Икенче яктан үзен-үзе юата: башка кайберәүләр белән чагыштырганда бәхетлерәк тә әле ул: шөкер, өчесе исән. Минзакиры кайтты, төпчеге дә срогы тулгач кайтыр, боерган булса. Хәзер, сугыш туктагач курыкмый инде. Исламының да тормышы җайга салынды: Әсма килен акыллы, сабыр, аның белән бик килешеп, тату яши. Мингәрәйнең ятимнәренә дә һич кырын карый белми, җан җылымлы сөйләшә

1948 елда, Исламның икенчесе—Әсләме туган елда, Сыктывкар шәһәреннән хат килеп төшә аларга: Фатыйх исән, бүгенге көндә шунда яши, гаиләсе дә бар икән. Аңа бер мәл еларга да, көләргә дә белми аптырый. Аннан акылына килеп кычкырып елап җибәрә, шатлык яшьләрен коя.

...Фатыйх кабат фронтка киткәч, Төньяк Кавказга эләгә. 1942 елның икенче яртысында гитлерчыларның удар ике юнәлешенең берсе өчен барган көрәшне киң тасвирлау мөмкин. Тауларда ишәкләр белән азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары ташып дошман басымына каршы торалар алар. Идел буенда, Сталинградта дошманны боҗрага кысып алгач, бу юнәлештәге гаскәрләрдә һөҗүмгә күчә. Тик бу хәрәкәтләрдә күп катнашырга туры килми аңа—әсир төшә. Үзе теләп түгел, әлбәттә.

Башта илебез территориясендәге, аннан Германия, Франциядә урнашкан концлагерьларда әсирлекнең тәмен татый. Аннан Италиягә күчерәләр. Итальян картына кол итеп саталар, шул ач үлемнән коткарып кала.

Аппенин ярымутравын американлылар азат иткәч, аны да туган иленә кайтмаска үгетләүчеләр табыла, әсирләрне рәхимсез эзәрлекләнүе турында кисәтәләр. Каламы соң ул—үлсә мәете туган җиренә күмелсен.

Торонто шәһәре янындагы лагерьдан Югославиягә озаталар. Анда барлык әсирләр дә тикшерү үтә. Тикшерүче аны да чакыра: «ни өчен әсирлеккә бирелдең?» «Мич башында ятмаганга»,—дип җавап бирә Миннебаев.

Бу сүзләрнең хикмәте шунда, әле һаман үпкәсендә пуля йөрткән Фатыйх, үзе теләп фронтка китүенә ишарәли. Әмма хак сүзләре тикшерүченең ачуын гына кабарта: башка әсирләрнең күбесе кебек үк Коми АССРга урман кисәргә озатыла.

Ярым-ярты саулыклы тоткын мондый авыр хезмәттә тиз бирешә. Хәлдән таеп егылган, үләсе көн кебек ачык Миннебаев госпитальгә килеп эләгә. Ул чакта үпкәгә операция катлаулылардан санала, шуңа моңа алынырга теләмиләр. Фатыйх операция ясауны үзе сорый.

—Шунда кадәрге 6 ел гомеремне яшәү белән үлем арасындагы тозакта дип санйым.—Фатыйх Мингалимович үпкәсендә пуля йөрткән ул еллары турында шулай дип искә ала. —Терелүгә өмет аз булса да, икеләнүсез операция өстәленә яттым.

—Сугыш беткәнгә өч ел вакыт үткән, туганнарыгызга бер хәбәр дә бирмәгәнсез. Ни өчен?—күптән күңелдә сакланган сорауны бирәбез.—Бу мөмкин түгел идеме?

—Мөмкин иде,—ди ул. Ләкин сез бер нәрсәне истән чыгарасыз. Алар өчен мин юк. Я үлгән, я хәбәрсез югалган хәбәрем килгән (ике тапкыр үлгән хәбәре килгәнен белми ул чакта) онытып бетергәннәр иде инде. Дөньяда барлыгымны, көн саен үлем көтеп яшәвемне белсәләр, аларга нинди хәсрәт булыр иде.

Аның белән килешергә, килешмәскә дә мөмкин. Сәламәтлеге тулы булмаган кешенең күңеле һәрчак китек була бит аның: үз-үзен дә күрәсе килми кайчак. Аның, шуның өстәвенә, үзенә башкалар ничек караганын аңламавы мөмкинме?! Хурлыклы исем тагылган булгач, туганнарын борчырга теләмәве бик ихтимал. Ничек булса да, бу хакта аның үзе белән ачыктан-ачык, иркенләп сөйләшү кыен. Ләкин бер нәрсә факт: ул шулай хәл иткән.

Операциядән соң Фатыйхның хәле уңайга китми, госпитальдә беркадәр яткач, бүтән барыр урыны булмаганга, инвалидлар йортына күчерәләр. Анда эшләүче Маруся аның хакында кызганып әнисенә сөйли. Аны үзләренә алып кайта.Ул Клавага ир,дүрт ятимгә ата була. Бары шуннан соң,, өй тәрбиясендә сәламәтлеге ныгыгач кына, Фатыйх үзенең дөньяда барлыгын белгертеп хәбәр сала.

Хәбәр Мингалим карт балаларын гына түгел, Киеклене аякка бастыра. Арада иң сөенгәне Хөбәйбә карчык була, билгеле. Хәл белергә кайткан улы сөйләгәннәргә генә ышанмыйча җыенып ерак җиргә, улының торган урынын күрергә чыгып китә. Елга якын торып иркенләп кунак булып кайта.

Тик шатлыклы еллар озакка сузылмый шул. Күргән тормыш кыенлыклары, хәсрәт, сагыш ананың гомерен кыскарта.

Әниләрен җирләгәч, Минзакир абыйсы, энесе Галиәскәр белән киңәшә дә, Ислам Сыктывкарга китеп бара, абыйсын үзләре янына алып кайта. Җиңги тиешле Клава төпләнгән нигездән кузгаласы килми, икеләнә. Әмма аннан барып алганны да көтми,, үзе кайтып төшә. Татар диненә күчеп, исемен Хәдичәгә алмаштыра. Алар Галиәскәр кебек Норлатка төпләнәләр. Ислам белән Минзакир авылда гомер кичерә. Һәркайсының бала-чагасы буй җиткән, оныклары бар. Бу яктан Исламнар иң алын:7 бала.Килен-кияүләр, оныклары, аларның баласын да кушып санасаң—алар инде 37 кеше.

Бөек Җиңү көнен каршылаганда, сугыш башланган көнне искә алганда да күңелләре гадәти горурлык кичерә алмый аларның. Һәркайсының Ватан сугышы ордены булса да, ил иминлеге өчен һәркайсы кан койган булса да, үз башларыннан үткәнне күз алдына китерәләр дә—йөрәкләрен сагыш баса, бизмәннең шул ягы тарта. Ни эшләмәк кирәк, чыны шулай ич.

**Гариф ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,**
хезмәт ветераны.
**Роберт АЙЗАТУЛЛИН,**
«Дуслык» газетасы корреспонденты.

## Тормыш сулышы

14 сәләтле баланы алу өчен психологларга 1000 баланы тикшерергә кирәк булган. Мәскәүдә соңгы вакытта балаларның акыл дәрәҗәсе түбәнәюе сизелә. Ә халыкара стандартлар буенча 20 баладан берсенең акыл үсеше югарырак булырга тиеш. Мәскәү балаларының мондый артта калуы экологик фаҗигаләр һәм туклануның тиешенчә дәрәҗәдә булмавы нәтиҗәсе.

x x x

РСФСР Югары Советы Президиумы РСФСР халык депутатларының бишенче (чираттан тыш) съездын 1991 елның 10 июлендә чакырга карар итте. Съезд көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләр кертелә: «РСФСР Конституцион суды турында» РСФСР Законын раслау; РСФСР Конституцион суды сайлау; РСФСР Президентының тантаналы ант итүе; оештыру мәсьәләләре.



